| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.06.2019 Балык Бистәсе штп. № 201пи

Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 16 апрелендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Кодексын раслау турында” 144пи номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнар белән тәңгәллеккә китерү максатларында, 2007 елның 2 мартындагы “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 25-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә КАРАР БИРӘМ:

1.Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 16 апрелендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Кодексын раслау турында” 144пи номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Муниципаль хезмәткәргә вазыйфаи хәле яки вазыйфаи йөкләмәләрен үтәү белән бәйле рәвештә физик һәм юридик затлардан әҗер (акчалата түләүләр, бүләкләр, ссудалар, хезмәт күрсәтүләр, күңел ачу, ял итү, транспорттан файдаланган өчен түләүләр һәм башка бүләкләр) алу тыела. Үзидарәлек хезмәткәре тарафыннан беркетмә чаралары белән бәйле, хезмәт командировкалары һәм бүтән рәсми чаралар вакытында алынган бүләкләр үзидарәлек милке дип таныла һәм үзидарәлек хезмәткәре тарафыннан, Россия Федерациясе Гражданнар кодексында тәгаенләнгән очраклардан гайре, акт буенча район Башкарма комитетына тапшырылалар. Беркетмә чарасы белән бәйле, хезмәт командировкалары яки бүтән рәсми чаралар белән бәйле рәвештә алынган бүләкне тапшырган үзидарәлек хезмәткәре аны Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә түләп алырга мөмкин.”;

1.2) 23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Җирле хакимиятне җитәкләүче үзидарәлек берәмлеге башлыгы белән якын туганлык яисә кода-кодагыйлык (каенишлек) (ата-ана, ир һәм хатын,

балалар, абый-энеләр, апа-сеңелләр, шулай ук ир белән хатынның абый-энеләре, апа-сеңелләре, ата-аналары һәм балалары) мөнәсәбәтендә булганда, әгәр үзидарәлек хезмәте вазыйфасын биләү әлеге вазыйфаи затка турыдан-туры буйсыну яисә контрольле булу белән бәйле, әгәр үзидарәлек хезмәте вазыйфасын биләү аларның берсенең икенчесенә турыдан-туры буйсынуы яисә контрольле булу белән бәйле булса.”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Җитәкче Р.Л. Исланов